ТАТАРСТАН Республикасы
Аксубай
муниципальрайоны
муниципаль беремлеге
ИСКЕ ИЛДЕРЕК АВЫЛЫ

Республика ТАТАРСТАН
Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
село Старое Ильдеряково

Совет Староильдеряковского сельского поселения

Сч. №40204810000000230012 к\сч.30101810000000000805 ИНН-1603000718 БИК 049205805
КПП-160301001 ОКПО- 94318576 ОАО «Ак Барс» Банк р.п.Аксубаево ЛБ 039140011 Ст Ил СП
Тел.: 4-47-30

**КАРАР**

**№88** **14.12.2024 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы "Иске Илдерәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Республикасы Конституциясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон , Татарстан , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрү һәм өстәмәләр кертү сәбәпле Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә 07.04.2020 ел №125 (в редакции решений от 16.12.2021 ел №38; 13.04.2023 № 59, 15.12.2023 ел карарлар редакциясендә.), Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы КАРАРы::

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Советының 07.04.2020 ел no 125 карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә.

2. Направить настоящее решение для государственной регистрации в установленном законодательством порядке.

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының "Иске Илдерәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә әлеге карарның текстын дәүләт теркәвенә алганнан соң «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук Аксубай муниципаль районының Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы бинасында урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.адресы: ТР, Аксубай районы, Иске Илдерәк авылы, Ленин ур., 71а йорт.

4. Әлеге карар дәүләт теркәвенә алынганнан һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы С.М. Маклаков

СОВЕТ СТАРОИЛЬДЕРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге
Советы карарына
№88 14.12.2024 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының « Иске Илдерәк авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү.

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
"21) "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык китапларында исәпкә алуны гамәлгә ашыру.";
3. 19 статьяның 5 өлешендә «1-7 пунктчаларында» сүзләрен «1-7 һәм 9.1 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;
4. 33 статьяның 1 пунктындагы 30 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«30) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе
4. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9,1 пункт өстәргә:
"9,1) аларга чит ил агенты статусы алу;";
5. 51 статьяның 9 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
"- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»
6. 48 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә::
"6) аның чит ил агенты статусын алуы;".
7. 67 статьяның 3 өлешендә "җирлек сайлау комиссиясенең," сүзләрен төшереп калдырырга;
8. 68 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә::
"12) әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа билгеле булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).";
9. 69 статьяның 2 пунктында", җирлек сайлау комиссиясен" сүзләрен һәм ", җирлек сайлау комиссиясе аппаратын " сүзләрен төшереп калдырырга.;

10.77 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «77 Статья»муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе"

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып торалар:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми

порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы сыйфатында теркәлү турында ФС77-60244 номерлы таныклык 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан яисә «Сельская новь» газетасында, №ФС7-4770 2007 ел, 30.11.2007 ел.;

2) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру http://aksubaevo.tatarstan.ru.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли, алар түбәндәге адреслар буенча урнашкан: 423064, Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Иске Илдерәк авылы, Ленин урамы, 71 а йорт Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы « Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне, халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарылудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы « Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.